# КАРАР

**19 июнь, 2023 ел** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Нырья авылында «Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Нырья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы Нырья авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 19 июнендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Нырья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы Нырья авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә Сез ризамы:

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«-Нырья авылының Комсомол урамындагы Авыл мәдәният йорты бинасын ремонтлау һәм төзекләндерү; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру»

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 167 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 86 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 86 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Нырья авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Нырья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы Нырья авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә Сез ризамы:

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«-Нырья авылының Комсомол урамындагы Авыл мәдәният йорты бинасын ремонтлау һәм төзекләндерү; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру»

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Нырья авыл җирлеге
башлыгы В.В. Васильев